ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӨРЕЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422737, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Бөреле җенлек совхозы, Божра., 33

СОВЕТ БИРЮЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422737, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п.Бирюлинского з/с, ул. Кольцевая, д. 33

Тел./факс: +7(84365) 76-5-45, e-mail: Brl.Vsg@tatar.ru

КАРАР
1 апрель 2019 ел

РЕШЕНИЕ
№ 97

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеген шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдәге законнарны башкару максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы 4 бүлеге, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы 5 бүлеге нигезендә, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләре булып торуын һәм авыл җирлекләре территориясендә муниципаль район җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеген шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын, кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча авыл җирлекләре бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе урынбасары,
авыл җирлеге башлагы урынбасары Т.Х.Багаутдинов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Бөреле авыл җирлеге
Советы Карарына
1 апрель 2019 ел № 97

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨРЕЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕН ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ ПРОЕКТЛАШТЫРУНЫҢ ҖИРЛЕ НОРМАТИВЛАРЫ

2019 ЕЛ

# ЭЧТӘЛЕК


1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР **Ошибка! Закладка не определена.**

2. ИСӘПЛӘҮ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕНЕҢ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ҺӘМ КУЛЛАНУ ӨЛКӘСЕ**Ошибка! Заклад**

3. БӨРЕЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНӘ КЫСКАЧА ХАРАКТЕРИСТИКА ..................................... 7

4. ТӨП ӨЛЕШ ............................................................**Ошибка! Закладка не определена.**

4.1. Авыл җирлеге халкын электр, җылылык, газ һәм белән тәэмин итү, су чыгару объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре ............................................................ 9

4.2. Авыл җирлекләре чикләрендә автомобиль юллары һәм җирлекнең, авыл җирлеге халкының җирле әһәмияткә ия булган объектларына караган транспорт объектлары белән тәэмин итүнең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре ........................................................... 10

4.3. Социаль яклауда мохтаҗ булган гражданнарның, авыл җирлеге халкының хокукларын тәэмин итүдә тормышка ашырыла торган торак төзелеше объектлары белән итүнең минималь дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре ............................................................................ 11

4.4. Авыл җирлеге халкының мәдәният, массакүләм ял, буш вакытны уздыру объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре.................................. 11

4.5. Авыл җирлеге халкының физик культура һәм массакүләм спорт объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре ........................................................ 12

4.6. Авыл җирлеге халкының информатизация һәм элемтә объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсе исәпләү күрсәткечләре ............................................................ 12

4.7. Авыл җирлеге халкының коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре ........................................................... 13

4.8. Авыл җирлеге халкының төзекләндерү һәм яшелләндерү объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре ............ 14
4.9. Авыл җирлеге халкының ритуал хезмәтләр күрсәтү объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре ............ 14
4.10. Авыл җирлеге халкының социаль тәэмин итү һәм социаль яклау объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре ............ 15
5. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ХАЛКЫНЫҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ БУЛГАН ОБЪЕКТЛАРГА, КҮРСӘТЕЛГӘН ОБЪЕКТЛАРНЫ УРНАШТЫРУГА НОРМАТИВ ИҖТЫЯҖЫН БИЛГЕЛӘҮГӘ РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР............ **Ошибка! Закладка не определена.**
5.1. Авыл җирлеге халкының электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару объектларында, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга норматив ихтыяҗларын билгеләүгә рекомендацияләр ............ 15
5.2. Авыл җирлеге халкының торак пункт чикләрендә урнашкан транспорт объектларында, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга норматив ихтыяҗларын билгеләүгә рекомендацияләр ............ 19
5.3. Торак төзелеше объектларын урнаштыруга рекомендацияләр ............ 19
5.4. Авыл җирлеге халкының мәдәният, массакүләм ял, буш вакытны уздыру, физик культура һәм массакүләм спорт объектларына норматив ихтыяҗын ачыклауга, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга рекомендацияләр ............ 20
5.5. Информатизация һәм элемтә объектларын урнаштыруга рекомендацияләр ............ 21
5.6. Авыл җирлеге халкының коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару объектларында, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга норматив ихтыяҗларны билгеләүгә рекомендацияләр ............ 22
5.7. Авыл җирлеге халкының төзекләндерү һәм яшелләндерү объектларында, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга норматив ихтыяҗларны билгеләүгә рекомендацияләр ............ 23
5.8. Зиратларны урнаштыруга рекомендацияләр ............ 23
6. ИСӘПЛӘҮ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕН НИГЕЗЛӘҮ БУЕНЧА МАТЕРИАЛЛАР**Ошибка! Закладка не о**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1.. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеген шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле  нормативлары (алга таба – нормативлар) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы норматив-хокукый актлары нигезендә эшләп чыгарылган.

1.2. Әлеге нормативлар белән җайга салынмый торган мәсьәләләр, Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган, “Техник җайга салу турында”, 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, законнар һәм норматив-техник документлар белән җайга салыналар.

1.3. Әлеге нормативлар үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге территориясендә тормышка ашыра торган, аларның оештыру-хокук формасына карамый, шәһәр төзелеше эшчәнлегенең барлык субъектлары өчен мәҗбүри.

1.4. Шәһәр төзелеше проектлавының  расланган җирле нормативлары, аларга үзгәрешләр кертү федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы  Бөреле авыл җирлеге җирде үзидарә органнары норматив хокукый актлары нигезендә тормышка ашырыла.

1.5. Әлеге нормативлар җирлекнең, авыл җирлеге халкының җирле әһәмияткә ия булган объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе исәпләү күрсәткечләренең барысын тәшкил итә; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре.

1.6. Авыл җирлеге халкының минималь мөмкин булган тәэмин итү дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре билгеләнә торган җирлекнең җирле әһәмияткә ия объектларына һәм авыл җирлеге халкы өчен әлеге объектларның территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләренә түбәндәге өлкәләргә караган объектлар  кертелә:

халыкны электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су чыгару;

торак пунктлар чикләрендә җире әһәмияткә ия булган автомобиль юллары, җирлекнең җирле әһәмияткә ия булган транспорт объектлары;

социаль  яклауга мохтаҗ булган гражданнарның хокукларын тәэмин итү буенча тормышка ашырыла торган торак төзелеше;

мәдәният, массакүләм ял, буш вакытны уздыру;

информатизация һәм элемтә;

физик культура һәм массакүләм спорт;

коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару;

төзекләндерү һәм яшелләндерү;

ритуал хезмәтләр күрсәтү;

социаль тәэмин итү һәм социаль яклау.

1.7. Нормативлар үз эченә түбәндәге бүлекләрне кертә:

төп өлеш (авыл җирлеге халкының минималь мөмкин булган тәэмин итү дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре билгеләнә торган җирлекнең җирле әһәмияткә ия объектларына һәм авыл җирлеге халкы өчен әлеге объектларның территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре);

нормативларның төп өлешендә булган исәпләү күрсәткечләрен нигезләү буенча материаллар;

нормативларның төп өлешендә булган исәпләү күрсәткечләренең куллану кагыйдәләре һәм өлкәсе;

авыл җирлеге халкының җирлекнең җирле әһәмияткә ия объектларына норматив ихтыяҗын билгеләүгә, әлеге объектларны урнаштыруга рекомендацияләр;

авыл җирлегенә кыскача характеристика.

## 2. ИСӘПЛӘҮ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕН КУЛЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ҺӘМ ӨЛКӘСЕ

2.1. Әлеге нормативлар белән билгеләнә торган исәпләү күрсәткечләре Бөреле авыл җирлеге территорияләренә карата эшләп чыгарыла торган Бөреле авыл җирлеген территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, килештергәндә, раслаганда һәм тормышка ашырганда кулланылалар.

2.2. Шәһәр төзелешен проектлау нормативлары дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары карарларын кабул итү, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарны контрольдә тоту һәм күзәтчелек органнары тарафыннан кулланылалар.

2.3. Җирле әһәмияткә ия объектлар исемлеге, әлеге нормативларның төп өлешендә китерелгән авыл җирлеге халкын тәэмин итүнең мөмкин булган минималь дәрәҗәсе исәпләү күрсәткечләре һәм авыл җирлеге халкы өчен әлеге объектларның территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре башкару өчен мәҗбүри булып тора.

2.4. Гамәлдә булган норматив документларны бетерү һәм (яки) үзгәртү, шул исәптән әлеге нормативларда сылтама бирелгәннәренә дә, бетерелгәннәре урынына кертелә торган нормалар белән җитәкчелек итәргә киңәш ителә.

## 3. БӨРЕЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНӘ КЫСКАЧА ХАРАКТЕРИСТИКА

3.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авлы җирлеге территориясенә кыскача характеристика, шулай ук халык саны, тыгызлыгы һәм социаль-демографик составы, башка характерлы үзекчәлекләре турында мәгълүматлар 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

| № т/б | Күрсәткечнең исеме | Характеристика |
|---|---|---|
| 1 | Авыл җирлеге территориясенең муниципаль район һәм Татарстан Республикасы структурасында урнашуы | муниципаль районның көнчыгыш өлешендә, Татарстан Республикасының төньяк-көнбатыш өлешендә |
| 2 | Авыл җирлеге чикләрендә территориянең гомуми мәйданы, га | 7072,14 |
| 3 | Авыл җирлеге составына керүче торак пунктларның исемлеге | Бөреле авылы<br>Бимер авылы<br>Керосиново авылы<br>Кирилловка авылы<br>п.ж.д.рзд.Бөреле авылы<br>Сосновка авылы |
| 4 | 2018 елның 1 сентябренә даими халык саны | |
| | барлыгы, кеше | 3183 |
| | торак пунктлар буенча, кеше:<br>Бөреле авылы<br>Бимер авылы<br>Керосиново авылы<br>Кирилловка авылы<br>п.ж.д.рзд.Бөреле авылы<br>Сосновка авылы | <br>2456<br>418<br>5<br>16<br>73<br>215 |
| 5 | 2018 елның 1 сентябренә халык тыгызлыгы, кеше,кв.метр | 45,01 |
| 6 | 2018 елның 1 сентябренә халыкның яшь структурасы | |
| | эшкә яраклы яшьтән яшьрәк халык, кеше | 640 |
| | эшкә яраклы яшьтәге халык (ир-атлар 16-59 яшь, хатын-кызлар 16-54 яшь), кеше | 1683 |
| | эшкә яраклы яшьтән олырак халык, кеше | 860 |

| | | |
|---|---|---|
| 7 | 2030 елга даими халык саны фаразы | |
| | барлыгы, кеше | 3255 |
| | торак пунктлар буенча, кеше:<br>Бөреле авылы<br>Бимер авылы<br>Керосиново авылы<br>Кирилловка авылы<br>п.ж.д.рзд.Бөреле авылы<br>Сосновка авылы | 2501<br>433<br>5<br>19<br>73<br>224 |
| 8 | 2018 елның 1 сентябренә авыл җирлегенең торак фонды | |
| | барлыгы, торак мәйданның мең кв.метры | 71 |
| | шул исәптән торак пунктлар буенча, торак мәйданның мең кв.метры:<br>Бөреле авылы<br>Бимер авылы<br>Керосиново авылы<br>Кирилловка авылы<br>п.ж.д.рзд.Бөреле авылы<br>Сосновка авылы | 9,9<br>1,8<br>2,4<br>6,3<br>4,6 |
| 9 | Халыкның торак белән тәэмин ителгәнлек дәрәҗәсе, кв.метр/кеше | 22,31 |
| 10 | Авыл җирлеге территориясендә табигать-климат шартлары | |
| | климатик район<br>(төзелеш өчен климатик районлаштыру картасы буенча) | IIВ |
| | сейсмик куркынычлык дәрәҗәсе (баллар) | 6 |
| | табигать-климат шартларына гомуми характеристика | уңайлы |

## 4. ТӨП ӨЛЕШ

### 4.1. Авыл җирлеге халкын электр, җылылык, газ һәм белән тәэмин итү, су чыгару объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре

4.1.1. Торак пунктларны төзүнең инженер җиһазлары системасын билгеләнгән тәртиптә эшләнгән һәм расланган территориаль планлаштыру документлары һәм авыл җирлеген су белән тәэмин итү, канализация, электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итү схемалары нигезендә проектларга киңәш ителә.

Әлеге тармак схемаларында технология, егәрлек, инженер челтәрләре күләме принципиаль мәсьәләләре хәл ителергә, схеманы тормышка ашыру буенча рекомендацияләр бирелергә тиеш.

4.1.2. Күрсәтелгән исәпләү күрсәткечләре 2 таблицада китерелгән.

2 нче таблица

| № т/б | Объектның исеме | Халыкны минималь мөмкин булган тәэмин итү дәрәҗәсе | Халык өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Электр белән тәэмин итү системасы объектлары:<br>электрлы трансформатор подстанцияләре, бүлү пунктлары, төрле көчәнештәге электр челтәрләре | торак һәм җәмәгать биналарының электр энергиясе белән 100 процент тәэмин ителгәнлеге; торак урамнарны 100 процент урам утлары белән тәэмин итү | билгеләнми |
| 2 | Җылылык белән тәэмин итү системасы объектлары, шул исәптән:<br>үзәкләштерелгән: котельлы, җылылык электростанцияләре, җылылык челтәрләре;<br>үзәкләштерелмәгән: автоном һәм шәхси котельлы, фатир, җылыылк генераторлы, җылылык челтәрләре | торак һәм җәмәгать биналарының җылылык энергиясе белән 100 процент тәэмин ителгәнлеге. | билгеләнми |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Үзәкләштерелгән газ белән тәэмин итү системасы объектлары:<br>газ бүлү һәм газ тутыру станцияләре һәм пунктлары, газ көйләү пунктлары; газ бүлү челтәрләре | торак биналарның газ белән 100 процент тәэмин ителгәнлеге. | билгеләнми |
| 4 | Үзәкләштерелгән су юелән тәэмин итү системасы объектлары:<br>су белән тәэмин итү чыганаклары, су алу җайланмалары, су саклау өчен урыннар, сүүткәргечләр | торак һәм җәмәгать биналарының су белән 100 процент тәэмин ителгәнлеге. | билгеләнми |
| 5 | Су бүлү системасы объектлары**, шул исәтән:<br>үзәкләштерелгән:<br>чистарту корылмалары, канализация насос станцияләре, канализация су торбалары;<br>үзәкләштерелмәгән:<br>локальчистарту корылмалары, юдыру җайланмалары, канализация су торбалары | торак һәм җәмәгать биналарының 100 процент тәэмин ителгәнлеге. | билгеләнми |

** исәпләү күрсәткечләре яңгыр канализациясенә кагылмый

**4.2. Авыл җирлекләре чикләрендә автомобиль юллары һәм җирлекнең, авыл җирлеге халкының җирле әһәмияткә ия булган объектларына караган транспорт объектлары белән тәэмин итүнең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре**

4.2.1. Автомобиль транспортының үтә алуы барлык биналарга һәм корылмаларга тәэмин ителергә тиеш.

4.2.2. Авыл җирлеге халкы өчен җәмәгать пассажир транспортының тукталыш пунктларының территориаль мөмкинлеге максималь мөмкин булган исәпләү

күрсәткечләрен 3 таблица нигезендә кабул итергә тиешле. Әлеге объектлар белән авыл җирлеге халкын минималь мөмкин дәрәҗәдә тәэмин итү исәпләү күрсәткечләре билгеләнми.

3 нче таблица

| № т/б | Объектның исеме | Халык өчен территориаль үтә алуның максималь мөмкин булган дәрәҗәсе (метрларда) |
|---|---|---|
| 1 | Торак пункт буенча тулаем алганда тукталу пунктлары | 500 |

**4.3. Социаль яклауда мохтаҗ булган гражданнарның, авыл җирлеге халкының хокукларын тәэмин итүдә тормышка ашырыла торган торак төзелеше объектлары белән итүнең минималь дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре**

4.3.1. Күрсәтелгән исәпләү күрсәткечләрен 4 таблица нигезендә кабул итәргә тиешле.

4 нче таблица

| № т/б | Объектның исеме | Халыкны тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе (кв. м/кеше) | | Халык өчен территориаль ала алуның максималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | 2030 ел | |
| 1 | Авыл торак пунктларында торак биналар | 23,1 | 26,4 | билгелнми |
| Искәрмә.<br>Киләчәккә исәпләү күрсшткечләре 2025, 2035 елларга ирешелгән торак биналарның гомуми мәйданы белән фактта минималь тәэмин итүне исәпкә алып төзәтмәләр кертелә. | | | | |

**4.4. Авыл җирлеге халкының мәдәният, массакүләм ял, буш вакытны уздыру объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре**

4.4.1. Күрсәтелгән исәпләү күрсәткечләрен 5 таблица нигезендә кабул итәргә

тиешле.

5 нче таблица

<table>
<tr><th>№ т/б</th><th>Объектның исеме</th><th>Халыкны тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе</th><th>Халык өчен территориаль ала алуның максималь мөмкин булган дәрәҗәсе</th></tr>
<tr><td>1</td><td>Түбәндәге халык саны белән торак пунктларда клуб учреждениеләре:<br>0,2 – 1 мең кеше<br>1 – 3 мең кеше</td><td>300 урын<br>300 – 230 урын</td><td>билгеләнми</td></tr>
<tr><td rowspan="2">2</td><td colspan="3">Түбәндәге халык саны белән авыл торак пунктларында авыл китапханәсе:</td></tr>
<tr><td>1 – 3 мең кеше</td><td>6 – 7,5 мең саклау берәмлеге;<br>5 – 6 урын 1000 кешегә</td><td>билгеләнми</td></tr>
<tr><td colspan="4">Искәрмә.<br>1. Кимрәк исәпләү күрсәткечен зур торак пунктлар өчен кабул итәргә киңәш ителә.<br>2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Карары нигезендә, 2019 елга халыкны клуб учреждениеләре һәм китапханәләр хезмәтләре белән тәэмин итү социаль гарантияләре дәрәҗәсе гамәлдә булган тәэмин итү дәрәҗәсендә кабул ителә.</td></tr>
</table>

**4.5. Авыл җирлеге халкының физик культура һәм массакүләм спорт объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре**

4.5.1. Күрсәтелгән исәпләү күрсәткечләрен 6 нчы таблица нигезендә кабул итәргә тиешле.

6 нчы таблица

| № т/б | Объектның исеме | Халыкны тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе | Халык өчен территориаль ала алуның максималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Спорт заллары | 1000 кешегә 350 кв.метр идән мәйданы | билгеләнми |
| 2 | Яссылыктагы яссылыктагы спорт корылмалары | 1000 кешегә 1950 кв.метр | билгеләнми |

**4.6. Авыл җирлеге халкының информатизация һәм элемтә объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре**

4.6.1. Авыл җирлеге халкын информатизация һәм элемтә объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләрен 7 нче таблица нигезендә кабул итәргә тиешле.

7 нче таблица

| № т/б | Объектның исеме | Исәпләү берәмлеге | Халыкны тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Почта элемтәсе бүлеге | авыл җирлегендә торак пунктлар | 1 |

4.6.2. Авыл җирлеге халкын тәэмин итүнең информатизация һәм элемтә объектлары белән тәэмин итүнең максималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре билгеләнмиләр.

**4.7. Авыл җирлеге халкының коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре**

4.7.1. Коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару объектлары исемлеге, андый объектларның урнашу урыны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге территориясен санитар эшкәртү Генераль схемасы нигезендә кабул ителә.

4.7.2. Авыл җирлеге халкын каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыклары (яшәү урыныннан, балалар һәм дәвалау-профилактика учреждениеләреннән, спорт мәйданчыкларыннан, ял итү урыннарыннан читтә булу) белән тәэмин итүнең максималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре 100 метр дип кабул итәргә тиешле.

**4.8. Авыл җирлеге халкының төзекләндерү һәм яшелләндерү объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре**

4.8.1. Авыл җирлеге халкын яшелләндерелгән территориялəр белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләрен 8 нче таблица нигезендә кабул итәргә тиешле.

8 нче таблица

| № т/б | Объектның исеме | Халыкны тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе (кв. м/кеше) | Халык өчен территориаль ала алуның максималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Авыл торак пунктларында гомуми кулланылыштагы территорияләрне яшелләндерү | 12 | билгеләнми |
| Искәрмә.<br>Урман, зур елга һәм сулыкларның яр буе зоналарында урнашкан торак пунктлар өчен гомуми кулланудагы яшелләндерелгән территория мәйданнарын киметү мөмкин, ләкин 20%тан да күбрәк түгел. | | | |

**4.9. Авыл җирлеге халкының ритуал хезмәтләр күрсәтү объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре**

4.9.1. Күрсәтелгән исәпләү күрсәткечләрен 9 нчы таблица нигезендә кабул итәргә тиешле.

9 нчы таблица

| № т/б | Объектның исеме | Халыкны тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсе (га/1 мең кеше) | Халык өчен территориаль ала алуның максималь мөмкин булган дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | Традицион күмү урынлы зират | 0,24 | билгеләнми |

**4.10. Авыл җирлеге халкының социаль тәэмин итү һәм социаль яклау объектлары белән тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре; әлеге объектларның авыл җирлеге халкы өчен территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре**

4.10.1. Халыкның инвалидларның шәхси автотранспортын даими саклау урыннары белән тәэмин итү дәрәҗәсен җиңел машиналарның даими саклау урыннарының гомуми саныннан 10% ка тигез дип кабул итәргә кирәк (ләкин 1 урыннан да ким түгел), шул исәптән кресло-коляскадага инвалидларның автотранспортлары өчен махсуслаштырылган урыннар саны 5%.

Халыкның инвалидларның шәхси автотранспортын вакытлыча саклау урыннары белән ачык мәйданнарда җиңел машиналарны учреждение һәм предприятиеләр янында кыска вакытка саклау өчен тәэмин итү дәрәҗәсен җиңел машиналарның вакытлыча саклау урыннарындагы гомуми саннан 10%ка тигех дип кабул итәргә (ләкин 1 урыннан да ким түгел).

## 5. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ХАЛКЫНЫҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ БУЛГАН ОБЪЕКТЛАРГА, КҮРСӘТЕЛГӘН ОБЪЕКТЛАРНЫ УРНАШТЫРУГА НОРМАТИВ ИҖТЫЯҖЫН БИЛГЕЛӘҮГӘ РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР

**5.1. Авыл җирлеге халкының электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару объектларында, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга норматив ихтыяҗларын билгеләүгә рекомендацияләр**

5.1.1. Электр белән тәэмин итү системаларын проектлаштыру электр чыганагында, “Торак һәм җәмәгать биналарын проектлау һәм монтажлау”, СП 31-110-2003 таләпләре (6 нчы бүлек), 2006 елның 2 нче июнендәге ОАО «ФСК ЕЭС»ның техник сәясәте турында Нигезләмә (2 бүлек) нигезендә, электр йөкләнеше күрсәткечләре нигезендә тормышка ашырырга тиешле.

Торак пунктлар территорияләрен чагыштырма исәпләү йөкләнешенең зурайтылган күрсәткечләрен алдан исәпләүләр өчен 10 нчы таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

10 нчы таблица

| Халык саны (мең кеше | Торак пункт | |
|---|---|---|
| | табигый газда булган плитәләр белән (кВт/кеше) | |
| | торак буенча | шул исәптән: |

| | барлыгы | үзәк | микрорайоннар /кварталлар, төзелешләр |
|---|---|---|---|
| Зтән ким | 0,41 | 0,51 | 0,39 |

Искәрмә.

1. Торак пунктның үзәге дигәндә, төрле административ, мәдәни, уку учреждениеләре, сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре күп җыелган территорияне аңларга кирәк.

3. Таблицада вак сәнәгать предприятиеләренең йөкләнешләре исәпкә алынмаган. Аларны исәпкә алу өчен түбәндәге коэффициентларны кулланырга кирәк:

табигый газдагы плитәләр белән торак пунктлар өчен: 1,2 – 1,6.

Зур күрсәткечләрне торак пунктның үзәге территориясенә кабул итәргә тиешле.

Электр энергиясен бүлү системасы көчәнешен сайлау Татарстан Республикасы электр челтәрләрен бүлү челтәрләр үсеше схемасы нигезендә, перспективадагы электр йөкләнешләре үсешенә анализ ясауны истә тотып, тормышка ашырылырга тиеш.

Электр челтәрләренең йөкләнеше аларның үсеш концепциясен исәпләү срогы кысаларында һәм йөкләнеш системасында истә тотып: 35 – 110 – 220 – 500 кВ яки 35 – 110 – 330 – 750 кВ сайлана.

Электр белән тәэмин итү йөкләнеше энергия трнсформациясенең иң аз күләмдә санын истә тотып сайланырга тиеш. Алдагы чорга бигрәк тә максатчан булган йөкләнеш системасы булып 35 – 110/10 кВ тора.

Транформатор подстанцияләрен һәм бүлү җиһазларын торак пункт территорияләрендә проектлауны Электр җайланмаларын урнаштыру Кагыйдәләре таләпләре һәм 2006 елның 2 нче июнендәге ОАО «ФСК ЕЭС»ның техник сәясәте турында Нигезләмә (2 бүлек) нигезендә тормышка ашырырга тиешле.

Торак төзелеш территориясендә урнашкан трансформатор подстанцияләре, бүлү җайланмалары һәм һавадагы электр тапшыру линияләренең кабельлегә күчү урыннарын ядык типтагы итеп проектлау киңәш ителә.

5.1.2. Җылылык белән тәэмин итү системаларының яңаларын проектлау һәм төзү, гамәлдәгеләрен төзекләндерү һәм үстерүне авыл җирлеген җылылык энергиясе белән тәэмин итүнең расланган схемасы нигезендә тормышка ашырырга тиешле.

Җылылык белән тәэмин итү системаларын проектлауны исәпләнгән җылылык йөкләнешләре күрсәткечләре нигезендә, кулланучыларның җылылык белән тәэмин итү ышанычлылыгы буенча категорияләрен истә тотып, “Җылылык челтәрләре” СНиП 41-02-2003 (5 бүлек), “Туры килүгә бәя. Күчемез милек объектларына экологик таләпләр” ГОСТ Р 54964-2012 (А кушымтасы) таләпләре нигезендә тормышка ашырырга кирәк.

Торак пунктлар территорияләрендә җылылык белән тәэмин итүнең үзәкләтерелгән чыганакларын коммуналь-склад һәм җитештерү зоналарында, җылылык йөкләнеше үзәкләрендә урнаштырырга киңәш ителә.

Җылылык белән тәэмин итү чыганакларын, җылылык пунктларын урнаштыру акустик исәпләүләр белән нигезләнгән булырга тиеш.

Трассалар һәм җылылык челтәрләрен салу ысулларын “Җылылык челтәрләре” СНиП 41-02-2003 (9 бүлек), “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” (12 нче бүлек) , СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89* таләпләре нигезендә күздә тотарга кирәк.

5.1.3. Газ белән тәэмин итү системаларының яңаларын проектлау һәм төзү, гамәлдәгеләрен төзекләндерү һәм үстерүне “Газ бүлү системалары” СНиП 42-01-2002 таләпләре, “Газ бүлү һәм газ куллану системалары иминлеге кагыйдәләре” ПБ 12-529-03, Татарстан Республикасын газ белән тәэмин итү һәм газификацияләү генераль схемасы нигезендә, торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газификацияләү республика программалары нигезендә тормышка ашырырга кирәк.

Авыл торак пунктлары өчен газ куллануның зурайтылган күрсәткечен бер кешегә бер елга 220 куб.м күләмендә дип кабул итәргә кирәк.

Газны бүлү һәм газ тутыру станцияләре торау пунктлар чикләрендә урнашырга тиеш.

Газ тутыру пунктларын торак пунктның торак төзелеш территориясеннән тыш, җилсез якта урнашытырырга кирәк.

Газ бүлү челтәрләрендә газ басымын киметү һәм җайга салу өчен газны көйләүче (блоклы яки шкафлы) пунктлар проектлаштырырга кирәк.

Газ көйләү пунктларын ул эшли торган район үзәгенә, районның йөкләнеш үзәгенә максималь якын итеп урнаштырырга кирәк.

Торак пунктларда аерым торучы газ көйләү пунктлары биналарга һәм корылмаларга аерым бер ераклыкта урнашытырырга кирәк:

газ көйләү пунктына кергәндә газның басымы вакытында 0,6 МПа га кадәр– 10 метр;

газ көйләү пунктына кергәндә газның басымы вакытында 0,6 – 1,2 МПа – 15 метр.

5.1.4. Су белән тәэмин итү системасын проектлаштыру, шул исәптән су белән тәэмин итү чыгынакларын сайлау, су бирү корылмаларын урнаштыруны “Эчке су үткәрү һәм биналарның канализациясе” СП 30.13330.2012 Актуальләштерелгән редакциядә СНиП 2.04.01-85*, “Су белән тәэмин итү. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар” СП 31.13330.2012 Актуальләштерелгән редакциядә СНиП 2.04.02-84*, “Шәһәр төзелеше.

Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” (12 бүлек), “Эчәр өчен су. Эчә торган су белән тәэмин итү үзәкләштерелгән системасында сының сыйфатына гигиеник таләпләр. Сыйфатны контрольдә тоту. Кайнар су белән тәэмин итү системалары иминлеген тәэмин итүгә гигиеник таләпләр” СанПиН 2.1.4.1074-01 , “Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итүдәге суның сыйфатына гигиеник таләпләр. Чыганакларны санитар саклау” СанПиН 2.1.4.1175-02 , “Хуҗалык-эчү өчен су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән чыганаклары. Гигиеник, техник таләпләр һәм сайлауның кагыйдәләре” ГОСТ 2761-84* , “Су белән тәэмин итү һәм эчү өчен билгеләнешле су торбаларын санитар саклау зоналары” СанПиН 2.1.4.1110-02 таләпләре нигезендә тормышка ашыралар.

Халыкның хуҗалык- эчү өчен ихтыяҗларына чагыштырмача уртача тәүлеккә (елга) су куллануның зурайтылган күрсәткечен түбәндәге күләмдә дип кабул итәргә кирәк:

эчке су үткәргеч һәм канализация, ванна һәм җирле су җылыту җайланмалары белән җиһазландырылган биналар өчен – бер кешегә бер тәүлеккә 200 литр су.

Су бирү корылмаларын урнаштыру тибын һәм схемасын сайлауны геологик, гидрогеологик һәм территориянең санитар шартларыннан чыгып башкарырга кирәк.

Су үткәрү челтәрләрен боҗралы итеп проектлаштырырга киңәш ителә. Чыгу булмаган линияле су үткәргечләрне куллану түбәндәге очракларда мөмкин:

җитештерү ихтыяҗлары өчен су бирү өчен, авария вакытында су белән тәэмин итүгә тәнәфес ясау мөмкинлеге булганда;

хуҗалык-эчү өчен ихтыяҗларга су бирү өчен торбаларның диаметрлары 100 мм.дан артмаганда;

суны янгынга каршы яи хуҗалык-янгын каршы ихтыяҗларга биргәндә янгын сүндерүгә суны сарыф итүне исәпкә алмый линиянең озынлыгы 200 метрлан артык булмаганда.

Тышкы су үткәрү челтәрләрен биналарның һәм корылмаларның эчке су үткәрү челтәрләре белән боҗралау рөхсәт ителми.

5.1.5. Торак пунктларның канализация системаларын проектлауны “Эчке су үткәрү һәм биналарның канализациясе” СП 30.13330.2012 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.04.01-85*, “Канализация. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар” СП 32.13330.2012 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.04.03-85*, “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” (12 бүлек) таләпләре нигезендә башкарырга кирәк.

Көнкүреш җыелган суларны уртача тәүлеккә чагыштырмача чыгару исәбе, территориягә һәм яшел утыртмаларга су сибүгә суны тотуга киткән чыгымнарны исәпкә алмый уртача тәүлеккә чагыштырмача куллануга тигез итеп кабул ителә.

Территориаль планлаштыру документларын эшләгәндә чагыштырмача уртача тәүлеккә (елга) авыл торак пунктларыннан суларны чыгаруны 1 кешегә 150 л/тәүлегенә күләмдә кабул итү рөхсәт ителә.

Агызылган суларны чистарту корылмалары мәйданын җылы чорда өстенлек иткән җилләр өчен торак пунктның торак төзелешенә таба җилсез яктан, су агымы буенча түбәнрәк урнаштырырга киңәш ителә.

**5.2. Авыл җирлеге халкының торак пункт чикләрендә урнашкан транспорт объектларында, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга норматив ихтыяҗларын билгеләүгә рекомендацияләр**

5.2.1. Торак пункт территорияләрендә урамнарның һәм юлларның уздыра алу мөмкинлеге автомобильләштерү дәрәҗәсеннән чыгып билгеләнә.

2030 елга кадәр авыл торак пунктлары өчен автомобильләштерү дәрәҗәсен 1000 кешегә 440 автомобильгә тигез дип кабул итәргә кирәк.

5.2.2. Җайга салына торган хәрәкәт булган магистраль урамнарда һәм юлларда уртача, зур һәм аеруча да зур авыл торак пунктларында төзелгән территорияләр чикләрендә җәяүлеләр чыгу урыннарын йөрү юллары белән бер дәрәҗәдә (җир өсте) 200-300 метр интервал белән күз алдында тотарга кирәк

5.2.3. Җәмәгать транспортының тукталу пунктлары арасында араны 400-600 метрга тигез дип кабул итәргә киңәш ителә.

5.2.4. Торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын һәм җирлекнең җирле әһәмияткә ия объектларына караган транспорт объектларын проектлаштыруны “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” (11 бүлек, И,К,Л кушымталары) СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89* таләпләре нигезендә башкарырга кирәк.

**5.3. Торак төзелеше объектларын урнаштыруга рекомендацияләр**

5.3.1. Торак төзелеше һәм торак төзелеш типлары күләмнәренең исәпләү күрсәткечләре булган һәм фаразлана торган социаль-демографик ситуацияне һәм халыкның керемнәре дәрәҗәсен исәпкә алып башкарылырга тиешле.

5.3.2. Торак төзелеше характеры нигезендә 11 нче таблицада күрсәтелгән төзелеш типлары күрсәтеләләр.

11 нче таблица

| № т/б | Торак төзелеш тибы | Төзелешкә характеристика |
|---|---|---|
| 1 | Аз катлы торак төзелеше | 3 катка кадәр кертеп шәхси йорт төзелеше;<br>3 катка кадәр кертеп блоклы торак йорт төзелеше;<br>4 катка кадәр кертеп күп фатирлы торак йорт төзелеше |
| 2 | Урта катлы торак төзелеше | 5 тән 8 катка кадәр кертеп күп фатирлы торак йорт төзелеше |
| 3 | Күп катлы торак төзелеше | 9 кат һәм аннан да биегрәк катка кадәр кертеп күп фатирлы торак йорт төзелеше |

Торак төзелеше типларын аеру, аларны оештыруга таләпләрне ачыклау авыл җирлегендә җиирдән куллану һәм төзелеш кагыйдәләре белән тормышка ашырыла.

5.3.3. Торак пунктларның торак төзелеше норматив параметрлары проектлаштыруны “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” 7 бүлеге, СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89* таләпләре нигезендә билгеләнелә.

**5.4. Авыл җирлеге халкының мәдәният, массакүләм ял, буш вакытны уздыру, физик культура һәм массакүләм спорт объектларына норматив ихтыяҗын ачыклауга, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга рекомендацияләр**

5.4.1. Авыл җирлеге халкының мәдәният, массакүләм ял, буш вакытны уздыру, физик культура һәм массакүләм спорт объектларында норматив ихтыяҗын билгеләүне өчен төрле социаль-демографик төркем халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерү кирәклеге нигезендә тормышка ашырырга кирәк.

5.4.2. Күрсәтелгән объектларны башка шундый ук объектларның якынлыгын, транспорт челтәрләрен оештыру, урамнар, юллар һәм җәяүле юллар челтәрләре белән бергәлектә булуын исәпкә алып урнаштырырга кирәк.

5.4.3. Мәдәният, массакүләм ял, буш вакытны уздыру, физик культура һәм массакүләм спорт объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең зурлыгы проектлаштыруга бирем нигезендә кабул итәргә киңәш ителә.

5.4.4. Физик культура һәм массакүләм спорт объектларын белем бирү мәктәпләре һәм башка уку йортлары, ял итү һәм мәдәният учреждениеләре белән берләштерү рөхсәт ителә.

**5.5. Информатизация һәм элемтә объектларын урнаштыруга рекомендацияләр**

5.5.1. Яңа төзелешне тормышка ашырганда телекоммуникацион челтәрләрне, эфирлы цифрлы телевидениене кабул итүнең коллектив системасын һәм өй эчендәге элемтә челтәрләрен эчке коммуникацияләр буенча сузуны, бер үк вакытта өч элемтә операторы хезмәт күрсәтә алырлык сыйдырышлылык белән урнаштыруны күздә тотарга кирәк.

5.5.2. Информатизация һәм элемтә объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең мәйданнарын 12 нче таблица нигезендә кабул итәргә.

12 нче таблица

| № т/б | Объектның исеме | Кишәрлекнең мәйданы |
|---|---|---|
| 1 | Почта элемтәсе бүлеге | 700 – 1200 кв. метр |
| 2 | Автоматлаштырылган телефон станциясе | 0,25 га |
| 3 | Төенле автоматлаштырылган телефон станциясе | 0,3 га |
| 4 | Концентраторлар | 40 – 100 кв. метр |
| 5 | Терәү-көчәйткеч станциясе | 0,1 – 0,15 га |
| 6 | Үткәргеч аша тапшыру  блок-станциясе | 0,05 – 0,1 га |
| 7 | Тавышлы трансформатор подстанциясе | 50 – 70 кв. метр |
| 8 | Кабель телевидениясенең техник үзәге | 0,3 – 0,5 га |

5.5.3. Элемтә предприятпеләренең биналарын күрше предпритие һәм зыян, коррозияле-актив, начар ис һәм тузан чыганагы булган технологик процесслы объектларга карата җилсез яктан (өстенлек итүче җилләргә карата), аларның санитар-саклау зоналарыннан тыш урнаштырырга кирәк.

5.5.4. Элемтә линияләрен урнаштыруны “Элемтә линияләре өчен җирләрне бирү нормалары” СН 461-74 таләпләре нигезендә тормышка ашырырга тиешле.

**5.6. Авыл җирлеге халкының коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгару объектларында, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга норматив ихтыяҗларны билгеләүгә рекомендацияләр**

5.6.1. Торак пунктларның торак зоналарында каты коммуналь калдыкларны җыю өчен автомобиль транспорты килә алырлык итеп контейнер мәйданчыкларын урнаштыруны күздә тотарга кирәк.

Кирәк кадәрле каонтейнер мәйданчыкларын ачыклау өчен контейнерла белән кулланучы халык саныннан, калдыклар җыелу нормасыннан, калдыкарны саклау срокларыннан чыгып эш итәргә кирәк. Контейнерларның исәпләү күләме калдыкларны иң күп барлыкка килгән чорында фактта аларның җыелуына туры килергә тиеш.

5.6.2. Коммуналь калдыклар җыелу нормасы күрсәткечләрен 13 нче таблицада китерелгән "Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү" СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89* таләпләре нигезендә кабул итәргә кирәк.

Җыела торган коммуналь калдыкларның санын вакыт-вакыт (һәр 5 ел) факттагы күрсәткечләр буенча тәгаенләп торырыга кирәк.

13 нче таблица

| Коммуналь калдыкларның төрләре | Коммуналь калдыкларның саны 1 кешегә бер елга | |
|---|---|---|
| | кг | литр |
| Каты:<br>су үткәргеч, канализация, үзәкләштерелгән җылылык һәм газ белән җиһазландырылган торак биналардан; башка торак биналардан | 190 – 225<br>300 – 450 | 900 – 1000<br>1100 – 2000 |
| Җәмәгать биналарын исәпкә алып кату коммуналь калдыкларның гомуми саны | 280 – 300 | 1400 – 1500 |
| Чокырлардан сыек (канализация булмаган очракта) | – | 2000 – 3500 |

5.6.3. Контейнер мәйданчыкларын торак йортлардан, балалар, дәвалау-профилактика учреждениеләреннән, спорт мәйданчыкларыннан һәм халыкның ял итү урыннарыннан 20 метрдан да ким булмаган ераклыкта урнаштырырга тиешле.

5.6.4. Бер мйданда урнаштырылган чүп-чар өчен контейнерлар саны 5

контейнердан артык булмаска тиеш.

5.6.5. Сыек коммуналь калдыкларны җыю өчен үзәкләштерелгән су чыгару системасы белән тәэмин ителмәгән торак төзелеше территориясендә ишегалд юынтык сулары урыннарын күздә тотарга кирәк.

**5.7. Авыл җирлеге халкының төзекләндерү һәм яшелләндерү объектларында, күрсәтелгән объектларны урнаштыруга норматив ихтыяҗларны билгеләүгә рекомендацияләр**

5.7.1. Торак пункт төзелеше чикләрендә төрле билгеләнешле яшелләндерелгән территорияләрнең чагыштырма авырлыгы (төзелеш территориясен яшелләндерү дәрәҗәсе) 55%тан да ким булмаска тиеш.

Төрле билгеләнешле яшелләндерелгән территорияләр дигәндә гомуми һәм чикле кулланылыштагы яшелләндерелгән территорияләрне, үзләре чәчелеп үсә торган агач һәм куаклык утыртмаларын, торак пункт территориясендәге урманнарны күздә тотарга кирәк.

5.7.2. Торак пункттагы яшел утыртмаларны бердәм система рәвешендә, аның планлаштыру структурасын һәм җирле шартларны истә тотып күздә тотарга кирәк.

Торак пунктның яңа территорияләрен проектлаганда һәм булганнарын төзекләндрегәндә, булган яшел утыртмаларны максималь рәвештә саклау һәм куллануны күздә тотарга кирәк.

5.7.3. Гомуми кулланылыштагы яшелләндерү объектлары мәйданнарын түбәндәге күләмнәрдә ге мәйданнарда кабул итәргә кирәк:

парклар –10 га дан ким түгел;

бакчалар – 3 га дан да ким түгел;

скверлар – 0,5 га.

5.7.4. Торак пункт территориясендә төзекләндерү һәм яшелләндерү объектларын урнаштыру принциплары, объектларның параметрларын “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” СП 42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89* таләпләре 9 бүлеге нигезендә кабул итәргә кирәк.

**5.8. Зиратларны урнаштыруга рекомендацияләр**

5.8.1. Әлеге бүлектә тәнне яки мәетнең калдыкларын җиргә иңдерү юлы белән җирләнә торган традцион күмү зиратларын урнаштыруга таләпләр һәм рекомендацияләр китерелә.

5.8.2. Зират өчен кишәрлекнең зурлыгы 40 га дан артмаска тиеш.

5.8.3. Зиратны урнаштырган вакытта халыкның, үлү коэффициенты киләчәктә артуын, эшләүче зиратлар булуын, бер җирләү урыны өчен җир кишәрлеге нормасын күздә тотарга кирәк.

5.8.4. Зиратларны торак пунктлар территориясенә карата җилсез яктан урнаштырырга киңәш ителә.

5.8.5.. Яңа күмү урыннарын булдыру, гамәлдә булган җирләү уралнарын төзекләндерү экологик һәм санитар-гигиеник экспертиза бәяләмәләре булган очракта мөмкин.

5.8.6. Авыл зиратларын торак, җәмәгать биналарыннан, спорт-сәламәтләндер һәм санатор-курорт объектларыннан 50 метрдан да ким булмаган ераклыкта урнаштырырга кирәк.

5.8.7. Зиратка бирелә торган кишәрлек түбәндәге таләпләрне канәгатьләндерергә тиеш:

торак пунктлардан, ачык сулыклардан һәм су агымыннан каршы якка авышлык булырга;

су басу мөмкин булган зонада урнаштырылмаска;

грунт сулары максималь күтәрелештә булганда җир өслегеннән 2,5 метрдан ким булмаган грунт сулары торышы дәрәҗәсендә булырга;

1,5 метр тирәнлектә һәм аннан да астарак коры, тишекле туфрак (көлсу, көлсу-кәсле), туфракның дымлылыгы 6-18% булырга .

5.8.8. Зиратлар территориясендә юл челтәрләрен, су сибү су торбасы яки шахта коесын, тышкы яктырту җайланмаларын күздә тотарга кирәк.

5.8.9. Күмү урыннары кишәрлекләренең зурлыгын 14 нче таблица нигезендә кабул итәргә кирәк.

14 нче таблица

| **Бер урында бер дәрәҗәдә күмүләр саны** | **Күмү кишәрлеге зурлыгы** | |
|---|---|---|
| | **Киңлеге, метр** | **Озынлыгы, метр** |
| 1 | 1,0 | 2,0 |
| 2 | 1,8 | 2,0 |
| 3 | 2,6 | 2,0 |
| 4 | 3,6 / 1,8 | 2,0 / 4,0 |
| 5 | 2,6 | 4,0 |
| 6 | 2,6 | 4,0 |

## 6. ИСӘПЛӘҮ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕН НИГЕЗЛӘҮ БУЕНЧА МАТЕРИАЛЛАР

6.1. Нормативлар түбәндәге норматив хокукый актлар таләпләре нигезендә әзерләнгән:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы 2004 елның 29 декабрендәге, 190-ФЗ номерлы Федераль закон;

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның;

“Җирләү һәм җирләү эше турында”, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон;

“Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында”, 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2014 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында”, 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары (30.05.2013 елга үзгәрешләр белән).

6.2. Нормативларны әзерләгәндә түбәндәге норматив документлар кулланылды:

42.13330.2011 Актуальләштерелгән редакция СНиП 2.07.01-89* “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” ;

СП 31.13330.2012 Актуальләштерелгән редакциядә СНиП 2.04.02-84* “Су белән тәэмин итү. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар”;

СП 32.13330.2012 Актуальләштерелгән редакциядә СНиП 2.04.03-85* «Канализация. Тышкы челтәрләр һәм корылмалар»;

СП 59.13330.2012 Актуальләштерелгән редакциядә СНиП 35-01-2001 «Биналар һәм корылмаларның азмобиль төркемнәре өчен керә алу мөмкинлеге»;

СанПиН 42-128-4690-88 «Торак пункт территорияләрен карап тотуга санитар кагыйдәләр»;

СанПиН 2.1.1279-03 «Зиратлар, җирләү өчен билгеләнешле башка биналар һәм корылмаларны урнаштыру, җиһазландыру һәм карап тотуга гигиеник таләпләр»;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 19 октябрендәге 1683-р номерлы Карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының социаль инфраструктура объектларында ихтыяҗ нормативларын ачыклау методикасы;

МДК 11-01.2002 «Россия Федерациясендә җирләү тәртибе һәм зиратларны карап тоту тәртибе турында рекомендацияләр»;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 27 декабрендәге

1071 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше проектлавының республика нормативлары;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы шәһәр төзелеше проектлавының җирле нормативлары.

6.3. Нормативларны әзерләгәндә исәпкә алындылар:

авыл җирлегенең административ-территориаль төзелеше;

авыл җирлегене социаль-демографик составы һәм тыгызлыгы;

табигать-климат шартлары;

Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеше программасы;

авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы;

җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынган затларның тәкъдимнәре.

6.4. Нормативларның төп өлешенедә авыл җирлеге халкын тәэмин итүнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре һәм әлеге объектларның территориаль ала алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәсен исәпләү күрсәткечләре өчен җирлекнең җирле әһәмияткә ия объектларының билгеләнгән исемлеге Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.2 статьясы 4 бүлеге таләпләре, шулай ук норматив проектларны эшләп чыгаруга техник бирем белән билгеләнгән.